КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2020 ел, 15 июль г.Казань № 593

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни-техник һәм инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясен төзү турында» 1999 ел, 10 декабрь, 810 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 23 август, 385 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Фәнни-техник һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

преамбулда «Фәнни-техник һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 һәм 2 нче пунктларда «Фәнни-техник һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Фәнни-техник һәм инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни-техник һәм инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе составын раслау турында» 2006 ел, 17 апрель, 175 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Фәнни-техник һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче пунктта «Фәнни-техник һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Фәнни-техник һәм инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1999 ел, 10 декабрь, 810 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 15 июль, 593 нче
карары редакциясендә)

Инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе турында нигезләмә

1. Инновацион сәясәт буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе (алга таба – Комиссия) инновация эшчәнлеге өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрү, дәүләт идарәсенең федераль законнар белән Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән аерым мәсьәләләре буенча бурычларны килештереп хәл итү өчен «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренә таянып төзелгән киңәшмә органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиянең бурычлары түбәндәгеләр була:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкаләтләре чикләрендә инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге чараларны үз эченә алган Россия Федерациясе дәүләт программаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү һәм тормышка ашыру буенча, шулай ук халыкара фәнни-техник һәм технологик хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлеген координацияләү;

в) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен тормышка ашыруга ярдәм күрсәтү һәм фәнни-техник, инновацион һәм сәнәгать сәясәтен системалы интеграцияләүне тәэмин итү;

г) фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, сәнәгать предприятиеләре, фәнни оешмалар һәм белем бирү оешмалары, үсеш һәм төбәк инновацион инфраструктурасының төбәк институтлары, технологик платформалар

һәм кластерлар һәм башка кызыксынучы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген арттыру.

4. Үзенә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру өчен Комиссия түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

а) фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек үсешенә комплекслы анализ ясауны тәэмин итә;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрен карап тикшерә:

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырыла торган фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек инфраструктурасын үстерү һәм интеграцияләнгән структураларны булдыру;

кыска вакыт эчендә һәм минималь чыгымнар белән конкуренциягә сәләтле фән сыйдырышлы продукция эшләп чыгарырга сәләтле кече һәм урта инновацион предприятиеләр челтәре аша фәнни эшләнмәләрне гамәлгә кертүнең иң нәтиҗәле юлларын кулланып, фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлекне үстерү;

Татарстан Республикасында интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм индивидуальләштерү чараларына хокуклар белән идарә итү системасының нәтиҗәлелеген арттыру;

конкуренциягә сәләтле фән сыйдырышлы продукцияне стимуллаштыру механизмнарын камилләштерү;

инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеген арттыру;

финанс үсеш институтлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерү;

в) финанс һәм матди-техник ресурсларның ихтыяҗларын нигезләүне, Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән алга таба тормышка ашырырга тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне, инновацион проектларны карап тикшерә;

г) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренә таянып, экспертиза узу нәтиҗәләре буенча фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне, инновацион проектларны алга таба аларны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тормышка ашыру өчен дәүләт программаларына кертергә тәкъдим итә.

5. Аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Комиссия билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмат (материаллар) соратып алырга;

б) үз утырышларына Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең вазыйфаи затларын чакырырга һәм тыңларга һәм тиешле карарлар кабул итәргә;

в) Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләрне эшләп бетерү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм белгечләре арасыннан эшче төркемнәр төзергә;

г) үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан башкаруга тәкъдим ителгән карарлар кабул итәргә.

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссиянең җаваплы секретаре һәм Комиссия әгъзалары керә.

7. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне Комиссия рәисе башкара. Комиссия рәисе булып Татарстан Республикасы Премьер-министры тора. Комиссия рәисе Комиссия утырышларын чакыра һәм алып бара, шулай ук Комиссия утырышларының көн тәртибен раслый.

8. Комиссия рәисе урынбасары:

а) Комиссия эшен оештыра;

б) Комиссия рәисе булмаганда аны алыштыра, шулай ук Комиссия рәисенең кушуы буенча Комиссия утырышларын чакыра һәм үткәрә;

в) Комиссия рәисенең башка йөкләмәләрен үти;

г) Комиссиянең Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлеген оештыра;

д) Комиссия карарларын тормышка ашыру һәм Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтәү максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә сораулар җибәрә һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыра, Комиссия эше турында Комиссия рәисенә тәкъдимнәр кертә;

е) бу Нигезләмәнең 5 нче пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә төзелгән эшче төркемнәр составларын һәм җитәкчеләрне Комиссиягә раслауга тәкъдим итә, аларның эшчәнлеген оештыра һәм аларның утырышлар беркетмәләрен раслый;

ж) Комиссия эшчәнлеген ачык яктыртуны оештыра һәм координацияли;

з) Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән алга таба тормышка ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыруны тәэмин итә.

9. Комиссиянең җаваплы секретаре:

а) Комиссия рәисенә һәм Комиссия рәисе урынбасарына Комиссия эшен оештыруда, шул исәптән Комиссиягә йөкләнгән бурычларны һәм Комиссия карарларын тормышка ашыру максатларында ярдәм күрсәтә;

б) Комиссия утырышларын әзерләүне оештыра;

в) Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләрне эшләп бетерү буенча эшче төркемнәрнең үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләре эшен координацияли;

г) Комиссиянең чираттагы утырышына материаллар әзерләү өчен Комиссия әгъзаларыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән кирәкле мәгълүматны соратып ала;

д) Комиссия карарлары проектларын әзерли һәм Комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи;

е) Комиссия карарларын һәм аның башка материалларын Комиссия әгъзалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары игътибарына җиткерүне оештыра.

10. Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия утырышында кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган регламент һәм эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Аерым мәсьәләләр буенча Комиссиянең эш тәртибе аның рәисе тарафыннан билгеләнә.

Бу Нигезләмәнең 5 нче пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә формалаштырылган эшче төркемнәрнең эш планнары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана.

11. Комиссия утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә. Комиссия утырышының көне, вакыты һәм урыны турындагы мәгълүмат Комиссия әгъзаларына утырыш үткәрелә торган көнгә кадәр кимендә 15 көн кала язма рәвештә җиткерелә.

12. Комиссия утырышы, әгәр дә анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия әгъзалары аның утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнаша. Әгәр дә Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаса, ул карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы.

Комиссия утырышында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча материаллар, шул исәптән дәүләт программаларына кертү һәм аларны алга таба Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тормышка ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр, инновацион проектлар буенча документлар исемлеге (аларның рейтинг нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең эксперт бәяләмәләрен теркәп) Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышы башланганга кадәр 15 эш көне кала бирелә.

13. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр дә утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге алар өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч тавыш була.

14. Комиссия утырышына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Комиссия составына кермәгән вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия утырышына чакырылган затлар исемлеге Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

15. Комиссия рәисенең хәл итүе буенча Комиссия карарларны Комиссия әгъзаларын язмача сораштыру юлы (читтән торып тавыш бирү) белән кабул итәргә мөмкин.

Карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча Комиссия әгъзасының фикере Комиссиягә тапшырыла һәм, әгәр дә сораштыру кәгазендә күрсәтелә торган, тавыш бирүне тәмамлау өчен билгеләнгән вакыттан соңга калмыйча бирелсә, исәпкә алына.

Читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәндә Комиссия әгъзаларының билгеләнгән вакытка бары сораштыру кәгазендә тавыш бирүнең мөмкин булган вариантларының берсе генә билгеләнгән мәсьәләләр буенча кергән тавышлары санала.

Әлеге таләпләрне бозып тутырылган сораштыру кәгазьләре гамәлдә түгел дип таныла һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәндә исәпкә алынмый. Читтән торып тавыш бирүне уздырганда, әгәр дә тавыш бирүдә катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала.

Тавыш бирүдә катнашкан Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч була. Әгәр дә Комиссия рәисе читтән торып тавыш бирүдә катнашмаса, тавышлар тигез булганда карар кабул ителмәгән дип санала.

Карар читтән торып тавыш бирүне үткәрү турындагы хәбәрдә һәм сораштыру кәгазьләрендә күрсәтелгән читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү датасына кабул ителгән дип санала.

Тутырылган сораштыру кәгазьләре читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча төзелгән Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә һәм аның аерылгысыз бер өлеше булып тора.

16. Комиссия утырышларында кабул ителә торган карарлар утырышта рәислек итүче тарафыннан имза куела торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия әгъзаларына һәм Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләрне карап

тикшерүдә катнашучы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына җибәрелә.

Комиссия утырышы беркетмәсе проекты Комиссия утырышын үткәргән көннән биш эш көне эчендә Комиссия рәисенә имза куюга кертелә.

17. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик һәм оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 17 апрель, 175 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 15 июль, 593 нче
карары редакциясендә)

Инновацион сәясәт буенча
Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе
составы

Песошин Алексей Валерьевич	Татарстан Республикасы Премьер-министры, комиссия рәисе
Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы	Татарстан Республикасы икътисад министры, комиссия рәисе урынбасары
Киреева Индира Радыковна	Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, комиссия секретаре

Комиссия әгъзалары:

Габделганиев Фәрит Солтан улы	Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча)
Абдуллажанов Эдвард Юныс улы	югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)
Агиев Шамил Рәхим улы	Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе (килешү буенча)
Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы	Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры
Әйделдинов Айнур Тәүфыйк улы	«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча)

Гафуров Илшат Рәфкать улы	югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)
Гыйльметдинов Альберт Харис улы	югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)
Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы	«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)
Зарипова Эльмира Әмир кызы	Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры
Җәббаров Марат Азат улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
Казаков Юрий Михайлович	югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча)
Кәримов Альберт Әнвәр улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры
Лаврентьев Александр Петрович	Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча)
Насыйбуллин Тимур Әнвәр улы	«Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча)
Низамов Рәшит Корбангали улы	югары белем бирүче «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)
Поминов Андрей Иванович	Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары
Садыйков Марат Наил улы	Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры
Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы	«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты

Салихов Айдар Рәиф улы	«Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе генераль директоры (килешү буенча)
Сафин Ленар Ринат улы	Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры
Синяшин Олег Герольдович	«Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге директоры (килешү буенча)
Созинов Алексей Станиславович	Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының югары белем бирүче «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)
Темиргалиев Тимур Фәрит улы	«Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча)
Тимирясова Асия Витальевна	югары белем бирүче «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты» шәхси мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)
Тормасов Александр Геннадьевич	югары белем бирүче «Иннополис университеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасы ректоры (килешү буенча)
Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы	Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры
Фәттахов Дамир Илдус улы	Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры
Хәйруллин Айрат Ринат улы	Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры
Хәлимов Ренат Азат улы	«Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)
Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы	Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры
Шаһивәлиев Тимур Наил улы	«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)

Шадриков Александр Валерьевич	Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры
Яруллин Рафинат Самат улы	«Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча).

_____